КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 гыйнвар г.Казань № 38

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 86 нчы «Өмет» интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе исемен үзгәртү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 86 нчы «Өмет» интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе исемен «Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 86 нчы «Өмет» мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (алга таба – үзгәртү) дип үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 30 көн эчендә учреждение Уставына үзгәрешләр кертергә.

3. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, бу карарның 2 пунктын үтәгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасының кайбер норматив хокукый актларын бу карарның 1 пунктына туры китерү өлешендә әлеге актларга үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин